**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ        Елаур ав.        КАРАР

«02» октябрь 2023        № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Петровский поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 16 октябрендә 11 сәгать 00 минутка Петровский поселогы, Лесная урамы 19нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Петровский поселогы Лесная урамындагы 2-32 нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Петровский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге поселок эчендәге юлларны ремонтлау (юл япмасын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш салу, транспорт хезмәтләре) шул исәптән поселок эчендәге юлларны сезонлы карап тоту;

роторлы чапкыч сатып алу;

«РИЗА»        «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова